ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 23 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән мәдәни мирас объектларын (алга таба шулай ук – бөтендөнья мәдәни мирасы объектлары) саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру гамәлләрен үтәүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин итү күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ статья өстәргә:

«$8^1$ статья. **Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән мәдәни мирас объектларын саклап калу һәм алардан файдалану**

Бөтендөнья мәдәни мирас объектлары белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм, әгәр тиешле

шартнамә (килешү) белән каралган булса, башка хуҗалык итү субъектлары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итеп, түбәндәгеләрне башкаралар:

1) Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән мәдәни мирас объектлары белән идарә итү планнарын гамәлгә ашыруны тәэмин итәләр;

2) Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән мәдәни мирас объектларының сакланыш торышын мониторинглауны оештыралар;

3) Берләшкән Милләтләр Оешмасы каршындагы Мәгариф, фән һәм мәдәният мәсьәләләре буенча бөтендөнья мирасы комитеты (ЮНЕСКО) таләпләре нигезендә 1972 елның 16 ноябрендәге Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасны саклау конвенциясе буенча халыкара йөкләмәләрне үтәү өчен кирәкле хисап документларын әзерлиләр.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 16 ноябрь
№ 81-ТРЗ